ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«21» декабрь 2022 ел

№ 1424

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларына йөрүче аерым категориядәге гражданнарга өстәмә социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 23 маендагы 534 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 2 августындагы 822 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясындагы 2 өлеше, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган аерым категорияләрдәге гражданнарга социаль ярдәм буенча өстәмә чаралар бирү максатларында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында йөрүче балаларга естәмә социаль ярдәм күрсәтү турында» 2022 елның 23 маендагы 534 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 02 августындагы 822 номерлы карарының 2 пунктына үзгәреш кертергә, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Мәдәниятне үстерү үзәге» муниципаль бюджет учреждениеләре, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Атказанган спорт мастеры Галимҗан Салих улы Хөсәенов исемендәге спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениеләре, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Ледок» хоккей буенча спорт мәктәбе» муниципаль автоном учреждениесе җитәкчеләренә 2022 елның 1 августыннан түбәндәге ташламаларны хәрби хезмәткәрләр (хезмәткәрләр), Нурлат районы буенча ведомстводан тыш саклау бүлегенең гражданлык персоналы затлары - «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы буенча ведомстводан тыш саклау идарәсе» дәүләт казна учреждениесе филиалы һәм янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләре өчен бирү мөмкинлеген карарга:

- Кама аръягы һәм Нурлат шәһәре Төбәк музеенда бушлай булу;

- «Тулпар» спорт сарае базасында атнасына бер тапкыр «Г.С. Хөсәенов исемендәге спорт мәктәбе» МБУ бушлай йөрү;

- «Ак Барс» спорт үзәге базасында «Ледок» хоккей буенча спорт мәктәбе» МАУда йөгерү чаңгыларын бушлай бирү (прокат)».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) (nurlat.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З.Р. Сәйфетдинова